2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авылы җирлеге Елховой авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

26 ноябрь 2025 ел № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлегенең Елховой авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Елховой авыл җирлеге Елховой авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлларына вак таш җәю); урам яктырткычларын урнаштыру (кабель һәм комплектлаучы СИП сатып алу һәм урнаштыру); Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияне төзекләндерү (Ватанны саклаучыларга һәйкәл-стелла ясау һәм урнаштыру); торак пункт территориясен төзекләндерү (парк зоналарында чатырлар сатып алу һәм урнаштыру).

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Елховой авылы, Совет урамы, 7А йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Елховой авыл җирлеге башлыгы А.А. Хәсәншин